**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге Күәм торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"29" ноябрь 2020 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Күәм торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Күәм торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
   -төзелеш материаллары сатып алу, Күәм авылы урам юлларын ремонтлау һәм төзекләндерү буенча хезмәтләр өчен түләү.
2. Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
   - Күәм авылы территориясен чистарту;
   - урамнарны кардан чистарту, транспорт хезмәтләре өчен түләү.
3. Күәм авылы Коммуна урамында күпер ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.
4. Күәм авылы Ленин урамындагы буага торба сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.
5. Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:
   - Күәм авылы зиратының ритуаль кирәк-яракларын саклау бинасы төзү өчен төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.

2020 елга гражданнар җыены буенча җыелган (экономияләнгән) үзара салым акчасын җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме?

1. Күәм авылы Л. Толстой урамында чишмәне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу), эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
2. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
   -төзелеш материаллары сатып алу, Күәм авылы урам юлларын ремонтлау һәм төзекләндерү буенча хезмәтләр өчен түләү.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Күәм авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы Гатауллин Р.Р.